**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы**
**муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“Күл-Черкен төп гомуми белем мәктәбе”**

| **“Каралды”** | **“Килешенде”** | **“Расланды”** |
|---|---|---|
| Методик берләшмә житәкчесе: | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары: | Директор: |
| ____ Абдуллина Р. М. | ____ *Гибадуллина Л.Р.* | ____ Камалтдинова Ә. Ә. |
| Беркетмә № 1 | | 133 номерлы боерык |
| “24” августа *2019* ел. | “27” август *2019 ел* | “31” август *2019* ел |

# I-IV сыйныфлар өчен “Туган тел” предметыннан эш программасы

реализацияләү срогы 4 ел

**Төзеделәр: Абдуллина Рина Мөнүр кызы**
**Камартдинова Зилә Рөстәм кызы**

Педагогик киңәшмә
утырышында кабул ителде.
Беркетмә № 1
“26” август 2019нче ел

Күл-Черкен авылы
*2019* нче ел

# 1. Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре

## 1 сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр:**

Үз илең, халкың һәм тарихың белән горурлану хисләре формалаштыру, һөнәрләр дөньясы белән танышу, җәмәгать урыннарында, мәктәптә үз-үзеңне тотуның әхлакый кагыйдәләрен үзләштерү,аңлы рәвештә рефлексив үзбәя формалаштыру:

- уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштыру,;
- әдәби мәдәният нигезендә матурлыкны күрә белү һәм эстетик хисләр формалаштыру

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- максатка ирешүдә үҗәтлек, авырлыкны җиңүгә әзер булу,авырлыкларны чишү ысулларын эзләүгә ихтыяҗ формалаштыру;
- план төзү һәм гамәлләр тәртибен ачыклау;
- ирешеләчәк нәтиҗәне алдан күрү;
- проблеманы чишүдә берничә вариант табу,аларны кулланып карау;
- үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;
- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре:**

- эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару;
- сызым, схема, таблица, шартлы рәсем, план, күчерү,үзгәртү, төзү;
- охшашлык һәм аермалыкларны аеру, чагыштыру;
- бербөтенне өлешләргә бүлү;
- аерып алынган нигез буенча объектларны тәртипкә салу;
- нәтиҗә чыгару;
- охшашлыклар урнаштыру;
- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- проблеманы чишү алымнарын хезмәттәшлектә табу;

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- укытучы, туганнар, эти-әниләр белән хезмәттәшлекне планлаштыру – катнашучыларның максатларын, вазифаларын үзара аралашу ысулларын билгеләү;
- дискуссиядә катнашу, сораулар формалаштыру, җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү;
- проблеманы ачу, аны тормышка ашыру, үзара килешүгә ирешү;
- эшлекле партнерлы аралашу, төркемдә үзара ярдәм итешү;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык , аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- барлык аваз һәм хәрефләрне танып белергә;
- аваз белән хәрефнең төп аермасын практик аңлауга ирешергә;
- сүзләрне авазларга тарката;
- авазларны сүздәге тәртиптә әйтү;
- сузык һәм тартык авазларны һәм аларның хәрефләрен аерып таный белү;
- калын һәм нечкә сузыкларны дөрес әйтү;
- сузык аваз һәм аларның хәрефләренә карап, калын һәм нечкә әйтелгән сүзләрне тану;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү;
- җөмләләрне сүзләргә таркату;
- баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу;
- басма, кулдан язылган хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу;
- әйтелеше һелән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый җөмләләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп дөрес язу;
- җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч нокта куеп язу;
- телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзү

## 2 сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр:**

дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;

- үзуңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үзэшчәнлегенең нәтиҗәләре няхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую).
- укучының өйрәнгән предметы (татар теле) буенча алган белем һәм күнекмәләре анық шәхес булып формалашуы өчен нигез була алу;
- уку һәм танып белүгә битараф булмау, тормышка актив караштa тәрбияләнү;
- ирешкән нәтиҗәләрнең баланың рухи-әхлакый үсешенә, сәламәт һәм хәвеф-хәтәрсез яши белүенә бәйле булу.

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үзэшчәнлегеңнеконтрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Танып-белү:**

- эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару;
- сызым, схема, таблица, шартлы рәсем, план күчерү, үзгәртү, төзү;
- охшашлык һәм аермалыкларны аеру, чагыштыру;
- бербөтенне өлешләргә бүлү;
- аерып алынган нигез буенча объектларны тәртипкә салу;
- нәтиҗә чыгару;
- охшашлыклар урнаштыру;
- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- проблеманы чишү алымнарын хезмәттәшлектә табу.

**Коммуникатив универсальукугамәлләре:**

- тормыштәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

дискуссиядә катнашу, сораулар формалаштыру, җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү;

- проблеманы ачу, аны тормышка ашыру, үзара килешүгә ирешү;
- эшлекле партнерлы аралашу, төркемдә үзара ярдәм итешү;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык , аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- сүзләрне, җөмләләрне, 30-40 сүзле текстны, хәрефләрен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча, аңлаешлы, пөхтә итеп, каллиграфик дөрес язу;
- сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны икеләнүсез аеру, анализ ясау, бирелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау,бирелгән аваз схемасына,характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү һәи иҗекләп юлдан-юлга күчерү;
- Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу;
- е,в,г,й,к,н,ң,о,ө,х,һ,э,ю,я хәрефләре, ый, йо,йө кушымчалары булган сүзләрне дөрес язу;
- янәшә килгән бертөрле ике тартык аваз хәрефләре булган әллә, кәккүк, Габбас кебек сүзләрне, нечкә(калын) аеру билгесе кергән гади, программада булган сүзләрне дөрес язу һәм юлдан – юлга күчерү;
- сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу;
- үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру;

-сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны ,предметның эшен,хәрәкәтен, билгесен, өстәмә предметны, ярдәмче сүзләрне таба белү;
-җөмләнең баш кисәкләрен таба бел-уку,уеннар, көндәлек тормыш, җәнлекләр, кош-кортлар турындагы темаларга 4-5 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу;
-сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: аваз,авыз, елга, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт, гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмбе, җавап, җомга, җөмлә, җылы, йөрәк, караңгы, көньяк, кыңгырау, маңгай, Мәскәү, муен, онык, оя, пәнҗешәмбе, савыт, сәгать, сәлам, сеңел, тавык, тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш, хайван, хөрмәт, һава, һаман, чаңгы, чәршәмбе, чия, шәһәр, шуа, эссе, юан, якшәмбе

## 3 сыйныф

**<u>Шәхси нәтиҗәләр:</u>**

дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

**<u>Метапредметлы нәтиҗәләр:</u>**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**:

- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү;
- үз фикереңне һәм позицияңне формалаштыру;
- уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килү;
- партнёрның нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә, сораулар бирү;
- партнёрның эш-гамәлләрен контрольгә алу;
- сөйләмнең диалог формасын үзләштерү.

**<u>Предметлы нәтиҗәләр:</u>**

кушма сүз, парлы сүз; тамыр һәм ясалма сүзләр; өйрәнелгән сүз төркемнәрен һәм аларның билгеләрен : исем, фигыль, сыйфат, зат алмашлыклары, алмашлык, кисәкчә, бәйлекләрне белергә тиеш;
- сүзләрдәге орфограммаларны табу һәм аларның язылышын кагыйдәләргә нигезләнеп аңлату;
- үтелгән орфограммалар кергән 55-60 сүзле текстны хатасыз һәм каллиграфик итеп күчереп һәм ишетеп, тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;
- сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерү;
- сүзнең тамырын һәм кушымчаларын табу;
- кушымчаларның төрен билгеләү;
- кушма һәм парлы сүзләрне билгеләү;
- сүзләрне сүз төркеме ягыннан тикшерү : исемнең сан, килеш кушымчасын билгеләү;
- сыйфатның дәрәҗәләрен аеру;

- фигыльнең зат – сан, заманын күрсәтү;
- текстның темасын, төп фикерен билгеләү;
- темага һәм төп фикергә таянып, текстка исем кую;
- текстның планын төзү;
- хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү һәм сөйләмдә куллану;
- культуралы мөгамәлә таләпләренә туры китереп, үтенеч, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, баш тарту, чакыру, котлау – тәбрикләү сүзләрен сөйләмдә куллану;
- тасвирлау һәм фикер һөртү элементлары кергән 70-75 сүзле хикәяне изложение итеп язу;
- хикәяләү характерындагы сочинение язу.
- кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.
- программада булган сүзләрне дөрес язу һәм юлдан –юлга күчерү
- сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу,
- үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру
- сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны ,предметның эшен,хәрәкәтен, билгесен, өстәмә предметны, ярдәмче сүзләрне таба белү
- җөмләнең баш кисәкләрен таба белү; уку, уеннар, көндәлек тормыш, табигать турындагы темаларга 7-8 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу
- сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: авыр,акбур,акош,алъяпкыч, ап-ак, аръяк, ашъяулык, аю,әдип,әти-әни, әһәмият, бала-чага, әһәмият, берәз, бияләй, булдыклы, буяу, вак, Ватан,гади, гаилә,гайртле, давыл, данә, дөя, егрле, елан, җәелә, җәза, җәнлек, җиз, җиһаз, илле, йокы, кадерле, карабүрек, кәгазь, кәккүк, кием, кошчык, котлы, көе, көнбагыш, көньяк,көянтә, куәтле, кúбрәк, күңелле, мәгънә, мәкаль, мәсьәлә, мәңге, милләт, морҗа, нәүрәз, ният, охшый, ошый, өрәңге,өянке, пөхтә, рөхсәт, русча, сава, салават, саңгырау, сәгать, сәламәт, сәхнә, сәяхәт, соңгы, сөенеч, сөяк, табигать,ташбака, таң, тәңкә, тиеш, тимераяк, тозсыз, төяк, төен, төнбоек, төньк, тыңлау, уйсу, үрмәкүч, чаңгы, чәучәк, чәүкә, чуар, чынаяк, шигырь, элекке, эре, юаныч, юаш, юкә, юлчы, юнәлеш, юына, ябалак, явыз, якты, ямьле, япь, ярдәм, ятьмә,яхшы, яшь.

## 4 сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- туган илгә карата шәхси караш булдыру;
- чын кеше сыйфатлары булдыру;
- мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү;
- этик хисләр, мөлаемлылык үстерү;
- рухи-әхлакый идеалларына китерү.
- олылар белән хезмәттәшлек;
- аралашу культурасы күнекмәләре .
- аралашу культурасы күнекмәләре

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**

- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

**Предметлы нәтиҗәләр:**

сүзләрдәге орфограммаларны танып, ал арның язылышын кагыйдәләргә нигезләнеп аңлату;

— үтелгән орфограммалар кергән 75—80 сүзле текстны хата¬сыз, каллиграфик күчереп һәм ишетеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;

— дөнья, болыт тибындагы сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау;

— сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү: тамырын һәм ку¬шымчасын табу, кушымчаларның төрен билгеләү, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү;

— сүзләрне сүз төркеме булу ягыннан тикшерү: исемнең сан, килеш формасын күрсәтү; сыйфатларның асыл, нисби төрен, чагыштыру дәрәҗәсен билгеләү; фигыльнең зат-сан, заманын аера белү; һәр сүз төркеменең җөмләдәге функциясен билгеләү;

— тиңдәш кисәкле гади җөмләгә, составында 2—3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләгә анализ ясау;

— җөмләләрнең әйтелү максаты, интонациясе буенча төрен икеләнмәстән аеру;

— текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, шулар ни¬гезендә аңа килешле исем кую;

— әдәпле мөгамәлә таләпләренә туры китереп аралаша белү;

— тасвирлау, фикер йөртү элементлары кергән 90—95 сүзле текстны изложение итеп язу;

— хикәяләү тибындагы сочинение язу;

— сүзләрнең әйтелешен, кулланылышын, язылышын истә калдыру: авыру, аз-маз, ата-ана, ашханә, аңлый, әби-бабай, әверелә, әүвәл, балачак, бәла, берничә, борынгы, вакыйга, ва¬тык, гадәт, гомер, дәвам, җәяү, җепшек, җиләк-җимеш, зинһар, иелә, ихтирам, йомры, кадәр, кием-салым, кульязма, көнбатыш, көнчыгыш, көрәшче, кыйммәтле, мал-туар, мәйдан, мәкалә, могҗиза, мөстәкыйль, нәкъ, охшаш, очсыз, өем, өчпочмак, пәрәвез, рәссам, савыт-саба, сәнгать, сөңге, сурәт, табиб, табигый, таләп, тәкъдим, тәмам, тирә-як, төер, туп-туры, тын¬гылык, чүп-чар, шагыйрь, шәфәкъ, шыңшый, эшчән, юеш, юньле, юучы, ямьле, ямь-яшел, япь-яшь.

# 2.Укыту предметының эчтәлеге

## 1 сыйныф

| Бүлек һәм темаларның исеме | Укыту темаларының эчтәлеге |
|---|---|
| Әзерлек чоры (Әлифбагача чор) | Язганда дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре белән танышу. Дәфтәр битләрендә ориентлашу, андагы сызыклар белән танышу. Язма хәрефләрнең өлге формалары белән танышу. Алгоритм буенча сызык элементлары язу. Бордюр-бизәкләр ясау процессында язма хәреф элементлары турында күзаллау тудыру. Эш формалары: төркемдә һәм парларда.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар язганда дөрес утыру, язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләрен, дәфтәр битендә ориентлаша, алгоритм буенча хәреф элементларын яза белергә тиешләр. |
| Төп чор (Әлифба чоры) | Дөрес утыру һәм язу әсбаплары дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү. Өлге элементларыннан язма хәрефләр төзү һәм анализлау. Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләрнең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Язуда өч төрле (өске, урта, аскы) тоташтыру алымы белән танышу. Сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртү һәм алга таба язма хәрефләр белән язу. Язма хәрефләр белән бирелгән иҗек, сүз, җөмлә үрнәкләрен уку, үрнәк буенча язу, укучыларның үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерүләре.<br>Эш формалары: төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар язуда өч төрле тоташтыру алымын кулланып, үрнәк |

| | |
|---|---|
| | буенча иҗекләр, сүзләр, җөмләләр, сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртеп, язма хәрефләр белән яза, үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерә белергә тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Татар халык мәкальләре, табышмаклар. |
| Йомгаклау чоры (Әлифбадан соңгы чор) | Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту. Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу, әйтеп яздыра торган текстны язу.<br>Эш формалары: төркемдә һәм парларда.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар язма һәм басма текстлардан сүзләр, җөмләләрне күчергәндә тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын куллана белергә тиеш.<br>Милли төбәк компоненты: Татар сүзләрен дөрес язу. |
| Алфавит | Хәрефләрне дөрес итеп уку (әйтү). Алфавиттагы хәрефләрнең урынын белү. Сүзлекләр төзүдә алфавитны белүнең әһәмиятен аңлау.<br>Эш формалары: экскурсия, төркемдә һәм парларда эшләү.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар татар алфавитындагы хәрефләрнең урыннарын һәм сүзләрне алфавит тәртибендә яза белергә тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Татар алфавитындагы хәрефләрне, татар сүзләрен дөрес язу, якташ татар язучыларының һәм шагыйрьләренең китаплары белән танышу |
| Җөмлә | Бүлекнең төп эчтәлеге:<br>Җөмлә турында беренче төшенчә белән таныштыру, андагы сүзләрнең һәрберсенең үз урыны булуын күзәтү. Төрле тавыш (интонация) белән әйтелгән җөмләләрдән соң куела торган тыныш билгеләре, аларны дөрес итеп кую. Телдән сөйләм белән язма сөйләмнең аермасын күрсәтү.<br>Эш формалары: төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар җөмләләрне, тыныш билгеләренә карап, дөрес интонация белән укый, телдән һәм язма сөйләмнең аермасын күрсәтә белергә тиешләр.<br>Контроль төрләре: парларда яки үз-үзеңне тикшерү.<br>Мөстәкыйль эшләр: биремле күчереп язу. |
| Сүзләр | Бүлекнең төп эчтәлеге:<br>Предмет атамасын белдергән сүзләр – исемнәр белән таныштыру, сорауларын әйтү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр һәм аларның язылышы. Ярдәмче сүзләр – бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән танышу. Предметның билгесен белдергән сүзләр, эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр белән таныштыру.<br>Эш формалары: төркемдә һәм парларда, индивидуаль.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар предметны, предметның билгесен, предметның эш-хәрәкәтен белдергән сүзләрне аера, ярдәмче сүзләрне таба, уртаклык һәм ялгызлык исемнәрнең язылышын белергә тиешләр.<br>Контроль төрләре: парларда яки үз-үзеңне тикшерү, сүзлек диктанты.<br>Мөстәкыйль эшләр: дидактик биремнәр.<br>Милли төбәк компоненты: Сүз турында татар халык мәкальләре. |
| Телдән һәм язма сөйләм | Бүлекнең төп эчтәлеге:<br>Телдән сөйләмнең үзенчәлекләре (интонация, сүз басымы). Язма сөйләм үзенчәлекләре (җөмлә башында, ялгызлык исемнәрдә баш хәреф). Әзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Сөйләм күнекмәләре булдыру өстендә эшләү. |

| | |
|---|---|
| | Эш формалары: төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар телдән һәм язма сөйләмнең үзенчәлекләрен, рәсем буенча җөмләләр һәм сөйләм төзи белергә тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Тел турында татар халык мәкальләре. |
| Иҗек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү | Бүлекнең төп эчтәлеге:<br>Сүзләр иҗекләргә бүленә. Иҗекнең үзәген сузык аваз тәшкил итә. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү иҗекләп башкарыла. ъ, ь, й хәрефләре булган сүзләрне иҗеккә бүлү һәм юлдан-юлга күчерү.<br>Эш формалары: төркемдә һәм парларда, индивидуаль.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар сүзләрне иҗекләргә һәм юлдан-юлга күчерү өчен бүлә белергә тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Туган як табигате. |
| Сузык аваз хәрефләре | Бүлекнең төп эчтәлеге:<br>Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Рус теленнән кергән сүзләрдәге сузыкларның әйтелешендәге аерманы күрсәтү. Э-е, ө-е, о-ы, я, ю, е хәрефләренең дөрес язылышы кагыйдәләре.<br>Эш формалары: төркемдә, парларда, индивидуаль, иҗади эшләр.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар э-е, ө-е, о-ы, я, ю, е хәрефләренең сүзнең төрле урыннарында дөрес язылышын, рус теленнән кергән сүзләрне дөрес итеп укый, күчереп һәм ишетеп яза белергә тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Туган якның гореф-гадәтләре. |
| Тартык аваз хәрефләре | Бүлекнең төп эчтәлеге:<br>Яңгырау һәм саңгырау тартыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Й хәрефенең язылу урынын истә калдыру. В хәрефенең ике төрле сүзләрдә кулланылуы, рус сүзләрендә бу хәрефне уку. К, г хәрефләренең калын һәм нечкә сузыклар булган сүзләрдә төрлечә укылуы, ң хәрефенең сүз башында килә алмавы, аның баш хәрефе булмау кагыйдәләре.<br>Эш формалары: төркемдә, парларда, индивидуаль.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аера белергә, в хәрефе кергән сүзләрне дөрес укырга, калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрдә к, г хәрефләрен дөрес әйтә белергә тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Татар халкының милли бәйрәмнәре. |
| Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту | Бүлекнең төп эчтәлеге:<br>Дәреслек ахырындагы әкият геройлары биргән сораулар һәм биремнәрне үтәү. Контроль күчереп язу. Ел буена өйрәнгәннәрне кабатлау.<br>Эш формалары: төркемдә, парларда, индивидуаль, иҗади эшләр.<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар җөмлә һәм җөмлә янында тыныш билгеләрен, предметны, билгене, эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләрен, сузык һәм тартык аваз хәрефләрен белергә тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Татар халык әкиятләре. |
| Барлыгы | |

## 2 сыйныф

| Бүлекнең исеме | Бүлекнең төп эчтәлеге |
|---|---|
| Фонетика һәм орфоэпия | Беренче сыйныфта алган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне ныгыту, тирәнәйтү.<br>Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр.<br>Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Парлы һәм парсыз яңгырау-саңгырау тартыклар. Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр. Татар теленә хас үзенчәлекле авазлар.<br>*Е, ю, я* хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, язу.<br>Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы.<br>Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе.<br>***ъ*** һәм ***ь*** хәрефләренең аваз белдермәгәнен истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес язу.<br>Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес итеп яттан белү. «Дөрес әйт», «Дөрес яз», «Аңлатмалы сүзлек» белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану. Беренче хәрефкә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру. |
| Графика | Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес итеп яттан белү. “””Дөрес әйт”, “Дөрес яз”, “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану. Беренче хәрефкә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру. |
| Сүз | Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. Татар телендә сүз тамырының сүз башында булуын, үзгәрмәвен, кушымчаларның тамыр сүзгә сингармонизм законына бәйле рәвештә ялганып килүен гамәли күзәтү.<br>Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.<br>Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның җөмләдә сүзләрне үз тирәсенә туплаган үзәк булуына төшенү.<br>Предметларның төрле билгеләрен атаган сүзләр. Аларны, Нинди? Кайсы? сораулары куеп, сүзләр арасыннан табу, җөмләдәге ролен гамәли күзәтү. |
| Җөмлә | Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү. Җыйнак һәм җәенке гади җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларны дөрес интонация белән әйтү. |
| Бәйләнешле сөйләм | Бәйләнешле сөйләмдә җөмләләрнең үзара бәйләнеше. Бер темага берләштерелмәгән аерым җөмләләрне текст белән чагыштыру. Текстның темасын билгеләү. Текстны кисәкләргә бүлү. Текст кисәкләренә исем кую.<br>Сюжетлы рәсемнәр буенча бер темага берләштерелгән җөмләләр төзү һәм язу.<br>Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау. Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану. |
| Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау | Авазлар һәм хәрефләрне; сүз, тамыр һәм кушымчаны;предметны, билгене, эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләрен,текст һәм текстның өлешләрен кабатлау. |

## 3 сыйныф

| Бүлекнең исеме | Кыскача эчтәлеге |
|---|---|
| Орфограмма. 1-2нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | Беренче һәм икенче сыйныфларда алган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне ныгыту, тирәнәйтү. Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тавышсыз хәрефләр. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Калын һәм нечкә сузык авазлар. Е,я,ю хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу. ъ, ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку. Сүзгә фонетик анализ ясау. |
| Сүз. Телнең сүзлек байлыгы | Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар. Аларның сөйләмдәге роле. Сүзнең күп мәгънәлелеген һәм күчерелмә мәгънәсен (фразеологик әйтелмәләр) куллану. Татар теленең сүз байлыгы. Дәреслекләрдәге сүзлекчәләрдән, сүзлекләрдән сүзнең аңлатмасын табып алу. Тотрыклы сүзтезмәләр. |
| Сүз төзелеше. Сүз ясалышы | Морфология һәм аның состав өлешләре. Бер тамырдан берничә сүз ясалу, кушымчалар, аларның яңа сүз ясаудагы роле.Тамырдаш сүзләр. Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре (ясалма, кушма, парлы сүзләр). |
| Сүз төркемнәре<br>Исем<br>Фигыль<br>Сыйфат<br>Алмашлык<br>Кисәкчәләр<br>Бәйлекләр | Сүз төркемнәре төшенчәсе. Исем. Исемнең предметлык төшенчәсен белдерүе, аның җөмләдә ия булып килүе. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрне тематик төркемләү. Исемнең берлек һәм күплек санда килүе. Күплек кушымчалары, аларның дөрес әйтелеше һәм ясалышы. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Сузык авазларга һәм яңгырау тартыкларга беткән исемнәрнең килешләр белән төрләнүе.<br>Фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары. Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыль өч заманы: үткән заман, киләчәк заман, хәзерге заман. Фигыльнең заман формаларын дөрес ясау. Фигыльнең күп мәгънәлелеге.<br>Сыйфатларның семантик төркемнәре. Сыйфат дәрәҗәләре (гади, чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләре).<br>Алмашлыкның мәгънә үзенчәлегенә –зат һәм предметны атамыйча, исемен генә алыштырып килүенә күзәтүләр. Зат алмашлыклары, килеш белән төрләнүе. Аларның җөмләләрне бер-берсенә бәйләүдәге роле.<br>*Да-дә, та-тә* кисәкчәләрен *-да/-дә, -та/-тә* кушымчаларыннан аеру. Кисәкчәләрне дөрес язу.<br>Төрле килешләрдә исемнәрне һәм зат алмашлыкларын *белән, саен, шикелле, өчен, аркылы, таба, хәтле, каршы, кадәр, чаклы, бирле, соң, башка* бәйлекләре белән куллану. |
| Җөмлә | Хикәя, сорау, өндәү (боеру), тойгылы җөмләләр. Аларны текстта аера белү.<br>Җөмләнең әйтелү максаты буенча төрләренә карап, җөмлә ахырына тыныш билгесе кую. Җөмләнең баш кисәкләре . Язма сөйләмдә ия һәм хәбәрнең урыннары.<br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак җөмләне, тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару. |

| | |
|---|---|
| Сүзтезмә | Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү, мәгънәләре, сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләр бәйләнешен ачыклау, сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне билгеләү. |
| Бәйләнешле сөйләм | Текстның темасын һәм төп фикере. Исемсез текстларның темасын билгеләү һәм исем кую. Төп фикерне темадан аера белү һәм аларны төгәл билгеләү. Текстның типлары: хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү. Аларның төп үзенчәлекләре.<br>Әзер яки күмәк төзелгән план буенча хикәяләү тибындагы текстны изложение итеп язу. Сюжетлы рәсемнәр һәм картиналар буенча укучыларның тормыш тәҗрибәсенә, күзәтүләренә, укыганнарына бәйле темаларга сочинениеләр язу. Телдән эш характерындагы текстлар төзү.<br>Сөйләм этикасы. Телдән һәм язмача чакыру, тәбрикләү. |
| Ел буена үткәннәрне кабатлау | Сүзнең төп(лексик) мәгънәсе. Синонимнар һәм антонимнар. Исем. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. Фигыль. Фигыльнең заман белән төрләнеше. Сыйфат. Сыйфат дәрәҗәләре. Алмашлык. Җөмләнең баш кисәкләре. Бәйләнешле сөйләм. Текст. Текстның планы. |

## 4 сыйныф

| Тема | **Эчтәлеге** |
|---|---|
| 1—3 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | 4 нче сыйныфта татар теле дәресләре 1—3 нче сыйныфларда алынган белемнәрне искә төшерүдән башлана.<br>1—3 нче сыйныфларда укучылар тел фәненең төп бүлекләре — татар теленең фонетикасы, морфологиясе һәм синтаксисы буенча иң беренче мәгълүматларны алалар.<br>Фонетикадан, мәсәлән, аваз һәм хәреф, алар арасындагы аерма, тартык һәм сузык авазлар, аерым авазларның дөрес әйтелеше, дөрес язылышы өйрәнелә, сингармонизм законы турында беренче күзаллау тудырыла. Морфология буенча башлап сүз төзелеше (тамыр һәм кушымча, кушымчаларның төрләре) һәм аерым сүз төркемнәре (исем, сыйфат, алмашлык, фигыль, кисәкчә, бәйлек) өйрәнелә. Синтаксистан исә җөмлә һәм аның төрләре (хикәя җөмлә, сорау җөмлә, өндәү (боеру) җөмлә, тойгылы җөмлә); җөмлә кисәкләре, җыйнак һәм җәенке җөмләләр, сүзтезмә турында башлангыч мәгълүматлар бирелә.<br>4 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау өлешендә фонетика, морфология һәм синтаксистан үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү күздә тотыла. Программада моңа барысы 8 сәгать бирелгән. |
| Сүз | күнегүләрдә сүзнең лексик мәгънәсе, алынма сүзләр, бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, омоним, синоним, антонимнарны искә төшерү бурычы куела. Татарча-русча яки русча-татарчй сүзлек, орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге белән эшләү күнекмәләре ныгытыла. |
| Сүз төзелеше | Сүз төзелеше . 4 нче сыйныфта кабатлау дәресләренең төп максаты — укучыларның 1—3 нче сыйныфларда алган белемнәрен искә төшерү.<br>«Сүз төзелеше» темасын кабатлау һәм тирәнәйтү өчен бирелгән күнегүләрдә дә тамыр һәм кушымчаларны аера белү, кушымчаларның ясагыч һәм төрләндергечләргә бүленүен, сүзләрнең ясалыш буенча төрләрен (кушма, парлы сүзләр) искә төшерү бурычы куела.<br>4 нче сыйныфта «сүз төзелеше» темасы тагын да тирәнәйтелә: ясалма, кушма, парлы, тезмә сүзләрнең ясалышы һәм язылышы; рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре; сүз төзелешенә анализ ясау һ.б. яңа темалар белән баетыла. Дәреслектәге кайбер күнегүләрдә өстәмә биремнәр рәвешендә кушымчаларның төрле вариантларын (калын һәм нечкә кушымчалар, яңгырау, саңгырау һәм борын авазларына башланган кушымчалар), |

| | |
|---|---|
| | сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә сүз ясагыч кушымчаларның ялгану тәртибен, кайбер кушма сүзләрдә ь һәм ъ хәрефләренең язылыш кагыйдәләрен аңлату һәм ныгыту да күздә тотыла. |
| Сүз төркемнәре. Исем | **Сүз төркемнәре**<br><br>Мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау. Исемнәрнең хәбәр булып килүләренә күзәтүләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Калын һәм нечкә төрләнеш. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгау. Килеш кушымчаларының дөрес язылышы.<br>Баш килеш. Бу формада исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярчен кисәк була алулары. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе.<br>«Исем» темасын кабатлау, ныгыту, тирәнәйтү.<br>Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше**.** Тартым кушымчаларының исемнәргә нинди мәгънә өстәгәнлекләрен аңлату өчен дәреслектән, 98 нче күнегү тәкъдим ителә. Күнегүдә тартымлы исемнәр калын хәрефләр белән бирелгән. Шул сүзләрне укытучы тамыр һәм кушымчаларга аерырга куша: *битләрем, авызым, колач-ым, күз-ләр-ем, теш-ләр-ем, кул-лар-ым.*<br>— Бу сүзләрдәге -ым/-ем кушымчалары исемнәргә нинди мәгънә өсти?<br>— Предметның ничәнче затка караганлыгын белдерә.<br>— *Битең, авызың; бите, авызы; битебез, авызыбыз; битегез, авыз-ыгыз; битләре, авыз-лары* сүзләрендә -ың/-ең; -ы/-е; -ыбыз/-ебез; -ыгыз/-егез; -лары/-ләре кушымчалары предметның ничәнче затка караганлыгын белдерә? кебек сораулар бирелә. Укучыларның җаваплары тыңлангач, билгеләмә укытыла. |
| Фигыль | **Фигыль**<br><br>**Фигыль** — катлаулы сүз төркеме.<br>Нишли? нишләде? сорауларына җавап булып килгән һәм предметның эшен, хәрәкәтен белдергән сүзләр 1 нче сыйныфта ук өйрәнелә. 2 нче сыйныф дәреслегендә эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр турында махсус бүлек кертелә һәм сораулар өстәлә: нишли? нишләде? нишләгән? нишләр? нишлиләр? нишләделәр? нишләгәннәр? нишләрләр?<br>3 нче сыйныфта фигыльнең барлыкта һәм юклыкта килүе; хикәя фигыльнең үткән, хәзерге һәм киләчәк заманнары; фигыльләрнең күп мәгънәлелеге буенча шактый тулы мәгълүмат бирелә.<br>4 нче сыйныфта 1—3 нче сыйныфта үткән материал искә төшерелә һәм хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары; киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат өстәлә.<br>Фигыль төркемчәләреннән боерык фигыль дә 4 нче сыйныфта өйрәнелә башлый. Аңа бирелгән өч сәгатьне түбәндәгечә бүләргә мөмкин: беренче сәгатьтә боерык фигыльнең мәгънәсен һәм зат-сан белән төрләнешен өйрәнеп, ике сәгатьне боерык фигыльне куллану һәм дөрес язуга бирергә була. Боерык фигыльләрнең язылышында I затның берлеге һәм күплеге кыенлык тудыра. Программада боерык фигыльләрнең И, III затта берлек һәм күплек формалары турында гына мәгълүмат бирү каралса да, укытучылар игътибарына боерык фигыльнең I зат берлеге һәм күплеге язылышына караган кагыйдәләрне тәкъдим итәбез:<br>1) Сузык авазга тәмамланган фигыльгә -ыйм/-им, -ыйк/-ик кушымчалары ялганганда, нигезнең соңгы сузыгы төшеп кала: кара*карыйм; телә — телим; төя — (төйә) — төй+им;укы -укыйм; төзе -төзим* һ. б. Ләкин *бие — (бийе) бий-им* түгел; бу очракта **й** язылмый һәм бу фигыльнең I заты *укы-, төзе-* фигыльләреннән ясалган кебек үк ясала: *биим, (төзим, ук-ыйм кебек).*<br>2) Нигезләре **[й]** һәм **[у]** авазларына тәмамланган фигыльләргә **-ыйм/-им**, **-**ыйк/-ик кушымчалары, тартыкка беткән фигыльләргә кушылгандагы кебек, бернинди үзгәрешсез ялгана: *ку-ыйм, шуыйм, җәйим, төйим.*<br>3) Фигыльнең нигезе дифтонгка тәмамланганда, ике сузык арасына туры килгән у урынына в языла: *сау* ----------------------------------------*савыйм, савыйк, савыгыз.*<br>Дәреслектә фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним һәм синоним фигыльләр турында да мәгълүмат бирелә. |

| | |
|---|---|
| Сыйфат | **Сыйфат**<br>Сыйфат — предметның билгесен белдерә торган сүз төркеме. Ул, нигездә, төрләнми. Тик кайбер сыйфатларны гына дәрәҗәгә куеп була. Җөмләдә сыйфат исемне ачыклап килә һәм күбесенчә аергыч була.<br>4 нче сыйныфта да, үтелә торган материалга бәйләп, сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатның җөмләдәге функциясе (аергыч, хәбәр), синоним һәм антоним сыйфатларны кабатлап баруны күз алдында тотарга кирәк. |
| Алмашлык | **Алмашлык**<br>**Алмашлык** — мөстәкыйль сүз төркеме. Ул сөйләмдә башка сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, сан һәм рәвешне) алыштырып килә. Алмашлык предметны яки билгене белдерми, ул бары тик үзе алыштырып килә торган сүз төркеменең грамматик билгеләренә ия була.<br>Укучылар алмашлыкларны, сүз төркеме буларак, 3 нче сыйныфта өйрәнә башлыйлар. Аларга бу сыйныфта нигездә зат алмашлыклары турында мәгълүмат бирелә. Зат алмашлыкларына мин — без, син — сез, ул — алар сүзләре керү, аларның җөмләдә исемне алыштырып килүләре, килеш белән төрләнүләре турында укучылар шактый тирән белем алалар, 4 нче сыйныфта зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы кабатлана һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат бирелә. Сорау алмашлыклары темасына кереп китү өчен, укучылардан килешләрне барлык сораулары белән әйттереп чыгарга кирәк.<br>Б. к. кем? нәрсә? И. к. кемнең? нәрсәнең? Ю. к. кемгә? нәрсәгә? кая?<br>Т. к. кемне? нәрсәне? Ч. к. кемнән? нәрсәдән? кайдан? Ур.-в. к. кемдә?нәрсәдә?кайда?кайчан?<br>Димәк, килеш сораулары сорау алмашлыкларына керәләр. Сорау алмашлыкларына тагын нинди, кайсы, ничек, ник, нигә, ничәнче кебек сүзләр керә. |
| Сан | **Сан** предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме. Сан исем белән кулланылганда төрләнми. Җөмләдә ул аергыч, хәбәр һәм исемнән башка кулланылганда, җөмләнең бүтән кисәкләре дә була ала. Мәсәлән: *Бүген кызларның <u>икесе</u> дә авырып китте. Дәрестә биш укучы шигырь сөйләде. Биш бишең — <u>егерме биш</u>.*<br>Фигыльне ачыклап килгәндә, сан хәл дә була. *Бер сорады, ике сорады — Азат чанасын бирмәде.*<br>Кайбер очракларда сан, саналмышы белән, бер җөмлә кисәге тәшкил итә: *Су коеныр*га икешәр мәртәбә барабыз. Мин дүртенче сыйныфта *укыйм.*<br>Сүз төркеме буларак, сан 4 нче сыйныфта өйрәнелә башлый. Укучылар санның билгеләмәсе (мәгънәсе, сораулары) белән танышалар. Санның исемне ачыклап килүе, сан белән ачыкланып килгән исемнең саналмыш булуы, кайбер сан төркемчәләре (микъдар саннары, тәртип саннары) турында беренче мәгълүмат алалар. |
| Рәвеш | **Рәвеш** — мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә.<br>Морфологик яктан — төрләнми. Тик кайбер рәвешләр генә чагыштыру яки артыклык дәрәҗәсендә килә алалар: Иң элек *бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән... (Г. Тукай). Мин быел чаңгыда **шәбрәк** йөрим.*<br>Синтаксик яктан — җөмләдә фигыльне, сыйфатны һәм рәвешне дә ачыклап килә.Төп синтаксик функциясе — хәл.<br>Укучыларга рәвеш турында башлангыч мәгълүмат 4 нче сыйныфта бирелә. Аның ничек? кайчан? кая? кайда? никадәр? күпме? кебек сорауларга җавап булып килүе, эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме булуы аңлатыла.<br>Рәвеш сүз төркемен өйрәнгәндә, фигыльне кабатлауга зур мөмкинлекләр бар, чөнки рәвеш күбрәк фигыльне ачыклап килә. Мондый мөмкинлектән файдаланырга тырышу бик урынлы. |
| Кисәкчәләр | **Кисәкчәләр т**урында беренче мәгълүмат 3 нче сыйныфта бирелә.<br>4 нче сыйныфта кисәкчәләрнең сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы ачыклана. Димәк, кисәкчәләр, аерым торганда, мәгънә белдерми, бәлки контекст эчендә генә аларның мәгънәләре конкретлаша икән. Бик күп кисәкчә күп мәгънәле була, һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә |

| | |
|---|---|
| | карап үзгәрә. |
| Бәйлекләр | **Бәйлекләр** Бәйлекнең ярдәмлек сүз төркеме булуы турындагы башлангыч төшенчә 1 нче сыйныфта бирелә, 2—3 нче сыйныфларда ныгытыла, тирәнәйтелә.<br>Ярдәмлек сүз булганга, төшенчәдә төп урынны бәйлекнең функциясе, үтәгән хезмәте алып тора: бәйлекләр сүзләрне бәйлиләр икән. Бәйлекләр, сүзләрне бәйләгәндә, килешкә якын мәгънә белдерәләр.<br>Бәйлекләр үзләреннән алда килгән сүзнең билгеле килештә торуын сорыйлар. Бу килешләр өчәү: *баш, юнәлеш* һәм *чыгыш килеше.* Шуңа карап, бәйлекләр дә өч төркемчәгә аерыла.4 нче сыйныфта төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат ал-машлыкларының бәйлекләр белән килүенә йомгак ясала, си-стемалаштырыла, бәйлек төшенчәсе грамматик категория итеп аңлатыла. |
| Җөмлә. Сүзтезмә | **Сүзтезмә** турында башлангыч аңлатма 3 нче сыйныфта бирелә. 4 нче сыйныфта сүзтезмәләргә шактый эзлекле мәгълүмат бирү күздә тотыла: сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын ныгыту, сүзтезмәдәге ияртүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү һ. б. |
| Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр | Бу тема 2—3 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне кабатлау төсендә бара.<br>Ия белән хәбәрнең билгеләмәсе әйттерелә, хәбәрнең сораулары мисаллар белән ныгытыла.<br>Җөмләдә бер мөстәкыйль исем яки зат алмашлыгы белән белдерелгән ияне табу кыенлык тудырмый. Исем мәгънәсендә килгән сүз яки сүзләр белән белдерелгән ияне табу да читен тү-гел. Шик туган очракта, аның я нинди исем урынында (мәгънәсендә) килүен ачыкларга, я җөмләнең хәбәре аша тикшереп карарга кирәк.<br>Гади хәбәр я бер мөстәкыйль сүз, яки бер тезмә сүз, яисә хәбәрлек сүз белән белдерелгәнгә, аны мөстәкыйль рәвештә танып белү кыенлык тудырмый. |
| Җыйнак һәм җәенке җөмләләр | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында 3 нче сыйныфта беренче мәгълүмат бирелде.<br>2 нче сыйныфта җыйнак җөмләне, тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару кебек күнегүләр эшләнә. |
| Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч | Бу материалны укучылар мөстәкыйль рәвештә дә үзләштерә ала. Әгәр дә алар, аергыч турында 2—3 нче сыйныфларда үткәннәрне исләрендә тотсалар, аергычка билгеләмәне һәм аның белдерелүен әйтеп бирә алалар. 4 нче сыйныфта аергычның сыйфат белән белдерелүе дәреслектәге — 91—94 нче, эш дәфтәрендәге 110 нчы күнегүләр өстендә ныгытыла. |
| Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең үзара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен төшендерү; тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлату. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр. Тиңдәш кисәкләр арасында һәм, я, да/дә, та/тә, ә, ләкин теркәгечләре, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре. |
| Эндәш сүзләр | Укучыларга эндәш сүзләр турында төшенчә бирү. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү. |
| Гади һәм кушма җөмлә | Гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә бирү. Составында 2—3 гади җөмлә булган кушма җөмләләр. Андый җөмләләрне тиңдәш кисәкле җөмләләрдән аера һәм аларны тикшерә белү. Тезмә кушма җөмләләрдә һәм, ә, ләкин, әмма теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре. |
| Текст. Бәйләнешле сөйләм. | Текст. Тема. Текстның өлеләре. Сөйләм этикасы. Хикәяләү, тасвирлау, фикерләү текстлары. |
| Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту | |

## 3.Тематик планлаштыру

### 1 сыйныф

| Бүлек һәм темаларның исеме | Сәгать саны |
|---|---|
| Әзерлек чоры<br>(Әлифбагача чор) | 6 |
| Төп чор<br>(Әлифба чоры) | 55 |
| Йомгаклау чоры<br>(Әлифбадан соңгы чор) | 2 |
| Алфавит | 3 |
| Җөмлә | 2 |
| Сүзләр | 4 |
| Телдән һәм язма сөйләм | 3 |
| Иҗек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү | 2 |
| Сузык аваз хәрефләре | 10 |
| Тартык аваз хәрефләре | 8 |
| Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту | 4 |
| Барлыгы | 99 |

### 2 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Сәгать саны** |
|---|---|
| Фонетика һәм орфоэпия | 43 |
| Графика | 6 |
| Сүз | 50 |
| Җөмлә | 10 |
| Бәйләнешле сөйләм | 11 |
| Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау | 16 |
| Барлыгы | 136 |

### 3 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Сәгать саны** |
|---|---|
| Орфограмма. 1-2нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | 12 |
| Сүз. Телнең сүзлек байлыгы | 11 |
| Сүз төзелеше. Сүз ясалышы | 10 |
| Сүз төркемнәре<br>Исем<br>Фигыль<br>Сыйфат<br>Алмашлык<br>Кисәкчәләр<br>Бәйлекләр | 66 |
| Җөмлә | 10 |
| Сүзтезмә | 2 |
| Бәйләнешле сөйләм | 12 |
| Ел буена үткәннәрне кабатлау | 13 |
| Барлыгы | 136 |

## 4 сыйныф

| Тема | **Сәгать саны** |
|---|---|
| 1—3 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | 8 |
| Сүз | 8 |
| Сүз төзелеше | 11 |
| Сүз төркемнәре. Исем | 8 |
| Фигыль | 13 |
| Сыйфат | 7 |
| Алмашлык | 6 |
| Сан | 6 |
| Рәвеш | 5 |
| Кисәкчәләр | 2 |
| Бәйлекләр | 2 |
| Җөмлә. Сүзтезмә | 2 |
| Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр | 2 |
| Җыйнак һәм җәенке җөмләләр | 1 |
| Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч | 2 |
| Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | 1 |
| Эндәш сүзләр | 1 |
| Гади һәм кушма җөмлә | 2 |
| Текст. Бәйләнешле сөйләм. | 8 |
| Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту | 7 |
| Барлыгы | 102 |